Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
14.10.2015 ел №12

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, «Җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 14.03.2013 №502 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районы сайтында.

3. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на заместителя руководителя исполкома Муниципального образования «поселок городского типа Джалиль» Сармановского муниципального района Республики Татарстан.

Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Калимуллина

Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктурасын 2025 елга кадәр комплекслы үстерү программасы

“Җәлил шәһәр тибындагы поселогы”
муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының
2015 елның 14 октябрендәге 12 номерлы
карары белән расланды

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ « ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ КОММУНАЛЬ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН 2025 ЕЛГА КАДӘР КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ |
| Программаны эшләү өчен нигез | « Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгының « Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге халкын коммуналь челтәрләрнең сыйфатлы хезмәтләре һәм җитәрлек күләмдә норматив сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итү, шуның нигезендә халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм социаль-икътисадый хәлне савыктыру бурычларын хәл итү турында карары. |
| Программаның төп уйлап табучылары | "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты |
| Программа клиенты | "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, районның коммуналь комплекс оешмалары, башка оешмалар |
| Программаның максатлары | Халыкны коммуналь челтәрләрнең сыйфатлы хезмәтләре һәм тиешле күләмдә норматив сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итү; шуның нигезендә халыкның сәламәтлеген яхшырту; « Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге территориясендәге социаль-экологик хәлне савыктыру. |
| Программаның бурычлары | -әлеге программаның максатларына ирешү өчен финанс, матди-техник ресурсларны, җитештерү потенциалын берләштерү;<br>- су сыйфаты күрсәткечләренең санитар нормалар таләпләренә туры килүен тәэмин итү өчен үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү объектларында |

| | |
|---|---|
| | гомумтөзелеш эшләре үткәрү;<br>- ташландык суларны агызу объектларында гомумтөзелеш эшләре үткәрү;<br>- суны экономияле тотуга юнәлтелгән чаралар үткәрү;<br>- торак пунктларда су белән тәэмин итүнең автоном чыганакларында су әзерләү һәм зарарсызландыру технологияләрен кертү буенча эшне дәвам итү<br>- төче су ятмаларын тикшерү һәм торак пунктларда скважиналарны төзекләндерү<br>- суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын реконструкцияләү. |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2015 – 2025 еллар |
| Программаны финанслауга ихтыяҗ күләме | Эшләнгән программа буенча |
| Программа үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Эшләнгән программа буенча |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисади күрсәткечләр | Программаны тормышка ашыру түбәндәге күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә тиеш:<br>торак төзелеше күләмен ел саен 0,5 мең кв. метрга кадәр арттыру;<br>су куллану күләмен тәүлегенә 105 дән 140 литрга кадәр җиткерү |